**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Туйкә авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Туйкә авылы № 18-7 «02» март 2026 ел.

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Советының 2016 елның 18 июнендәге 36-15 номерлы карары белән расланган 31.10.2016 №43-21,25.09.2017№69-33, 16.02.2018 №87-41, 30.12.2019 №158-73, 24.04.2020 №170-77, 27.10.2021 №39-21, 07.04.2023 №75-41, 25.09.2023 №86-48, 01.02.2024 №97-53, 18.11.2024 № 120-69, 27.5.2025№138-80 карарлар редакциясендә) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында.

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 15 декабрендәге 471-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә

Туйкә авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Советының 2016 елның 18 июнендәге 36-15 номерлы карары белән расланган 31.10.2016 №43-21,25.09.2017№69-33, 16.02.2018 №87-41, 30.12.2019 №158-73, 24.04.2020 №170-77, 27.10.2021 №39-21, 07.04.2023 №75-41, 25.09.2023 №86-48, 01.02.2024 №97-53, 18.11.2024 № 120-69, 27.5.2025№138-80 карарлар редакциясендә) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 һәм 4 бүлекләрне гамәлдән чыгарырга.

1.2. 5 бүлекнең 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмләне өстәргә: «Әлеге пункт белән каралган унитар предприятиеләрнең, акционер җәмгыятьләрнең һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрнең дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планнарына (программаларына)

кертелгән арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсын формалаштыру максатларында тәкъдим ителергә тиеш түгел.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Р.Р.Закирова